**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LI СЕССИЯСЕ**

**КАРАР №88**

**Иске Карамалы авылы** **21 нче гыйнвар 2025 ел**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Карамалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Карамалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә турында» 2023 елның 17 нче маендагы 58 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Прокурорының 2025 елның 14 гыйнварындагы 02-08-01-2025 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Карамалы авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Карамалы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Карамалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә турында» 2023 елның 17 нче маендагы 58 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 бүлекнең 8.3 пунктындагы 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) белем һәм квалификация турында документ;".

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам

Мөслим муниципаль районынын
Иске Карамалы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Кәримов